РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00


РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 17

2020 елның 21 феврале

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган (Советның 2016 елның 20 октябрендәге 59 номерлы, 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 10 номерлы, 2018 елның 17 маендагы 38 номерлы, 2019 елның 6 июнендәге 34 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасының Законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган (Советның 2016 елның 20 октябрендәге 59 номерлы, 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 10 номерлы, 2018 елның 17 маендагы 38 номерлы, 2019 елның 6 июнендәге 34 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» 6 статьясында 6.4 пунктында «2019 елның 1 гыйнвары» сүзләрен «2022 елның 1 гыйнвары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «Муниципаль хезмәткәрләрнең классы чиннары» 7 статьясында 7.2 пунктында «Татарстан Республикасында» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында мәгълүмат бирү» 14.1 статьясында:

а) 14.1.2 пунктында «әлеге статьяның 1 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 14.1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(1 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга,

б) 14.1.3 пунктында «әлеге статьяның 1 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 14.1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. «Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы» 26 статьясында 26.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «26.3. Дисциплинар җәза куллану һәм аклау

тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.5. «Муниципаль берәмлектә кадрлар эше» 28 статьясында 12 пунктында «әлеге Федераль законның» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары (Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге 59 номерлы карары редакциясендә) белән расланган 2 нче кушымтаның нумерацион исеменә түбәндәге сүзләр өстәргә: «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пунктчасының гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт узуга кагылышлы норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы — А.Р.Метшин